| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 гыйнвар 2022 ел № 04

Яр Челлы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 5 пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмәнең 12 пунктының 9 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 22 декабрендәге 8052 номерлы;

2) «Башкарма комитетның 2017 елның 22 декабрендәге 8052 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 5519 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 11 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә
шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы
арткан өчен түләү күләмен билгеләү
тәртибе

1. Әлеге тәртип Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен (алга таба – түләү күләме) билгеләү кагыйдәләрен регламентлаштыра.

2. Түләү күләме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участокларына карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан исәпләнә.

3. Түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә дип билгеләргә (әлеге тәртипнең 4 пункты белән билгеләнгән очрактан тыш):

$$Р_{п} = (П_{2} - П_{1}) \text{ х } УПКС_{чс},$$

монда:

$Р_{п}$ – түләү күләме;

$П_{2}$ – булдырылган шәхси милектәге җир участогының мәйданы, яңадан бүлү турында килешү нигезендә;

$П_{1}$ - яңадан бүлү турында килешү төзегәнгә кадәр шәхси милектәге элекке җир участогының мәйданы;

$УПКС_{чс}$ – яңадан бүлү нәтиҗәсендә мәйданы арта торган шәхси милектәге җир участогы өчен кадастр бәясенең чагыштырма күрсәткече. $УПКС_{чс}$ җир участогының кадастр бәясен аның мәйданына бүлү юлы белән билгеләнә (сум/кв. метр).

4. Татарстан Республикасы ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен булдырылырга тиешле җир участокларын алга таба алу максатларында җир участоклары яңадан бүленгән очракта, түләү күләме җир участокларын яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә бирелергә тиешле Татарстан Республикасы милкендәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир участогы өлешенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнарга таянып билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева